ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең исемендә «транспортта» сүзеннән соң «һәм автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

2) 5.1 һәм 5.2 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.1 статья. **Пассажир тарафыннан транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, шулай ук пассажир тарафыннан түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау тәртибен бозу**

Пассажир тарафыннан транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, ул транспортта йөргән яисә балаларны йөрткән өчен түләргә тиеш булган очракларда, шулай ук пассажир шәһәр, шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәсендә Татарстан Республикасы чикләрендә билгеләнгән

даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча йөргәндә түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау тәртибен бозган өчен –

ике мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.

5.2 статья. **Пассажир тарафыннан багаж ташыган, кул йөген йөрткән өчен түләүне раслау тәртибен бозу**

Пассажир шәһәр, шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәсендә Татарстан Республикасы чикләрендә билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча йөргәндә багаж ташыган, кул йөген йөрткән өчен түләүне раслау тәртибен бозган өчен –

бер мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

3) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 статья өстәргә:

«5.9 статья. **Транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәмәү**

1. Транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәмәгән өчен, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, –

бер мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.

2. Йөк транспорт чарасы яисә автобус региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәмәгән өчен –

биш мең сум күләмендә административ штраф салына.

Искәрмәләр:

1. Әлеге статьяда каралган административ җаваплылыкка тартылган һәм транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләү кертү бурычын административ хокук бозу турындагы эш буенча карар чыгару көненнән алып егерме көннән дә соңга калмыйча үтәгән зат административ җаваплылыктан азат ителә, ә әлеге административ хокук бозу хакындагы эш туктатылырга тиеш. Административ җаваплылыкка тартылган затка почта аша заказлы почта хаты белән җибәрелгән административ җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе аның адресына мондый карарны чыгару көненнән соң егерме көн узганнан соң килгән очракта, күрсәтелгән срок Административ хокук

бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.2 статьясындагы $1^3$ өлешендә каралган тәртиптә торгызылырга тиеш.

2. Транспорт чарасы милекчесе (хуҗасы), әгәр әлеге статьяның 1 яисә 2 өлешендә каралган административ хокук бозу мондый административ хокук бозу фотога һәм кинога төшерү, видеога язу функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чаралар яисә фотога һәм кинога төшерү, видеога язу чаралары белән беренче тапкыр фиксацияләнгәннән соң һәр транспорт чарасына карата бер тәүлек эчендә ике һәм аннан артык мәртәбә фиксацияләнгән булса, мондый административ хокук бозу фиксацияләнгән тәүлек эчендә икенче һәм аннан соңгы очраклар өчен административ җаваплылыкка тартылмый.»;

4) 7.6 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6 статья. **Транспорт комплексында, шул исәптән пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә, дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы орган**»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Транспорт комплексында, шул исәптән пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә, дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы орган әлеге Кодексның 5.1, 5.2, 5.6 (муниципальара пассажирлар йөртүгә карата), 5.9 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.»;

5) 8.1 статьяның 14 өлешендә «5.2» саннарыннан соң «(тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөртүләргә карата)» сүзләрен өстәргә;

6) 8.3 статьяда «3.16, 3.17» саннарыннан соң «, 5.9» саннарын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 25 декабрь
№ 110-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН